1997 елның 29 августында
Иҗтимагый берләшмәләрнең
гамәлгә кую съезды тарафыннан
РАСЛАНДЫ

2012 елның 8 декабрендә
«Бөтендөнья татар конгрессы»
иҗтимагый берләшмәләренең
халыкара берлеге V съездында
РАСЛАНДЫ

2017 елның 3 августында
«Бөтендөнья татар конгрессы»
иҗтимагый берләшмәләренең
халыкара берлеге VI съездында
РАСЛАНДЫ

**«Бөтендөнья татар конгрессы»**
**иҗтимагый берләшмәләренең**
**халыкара берлеге**

# УСТАВЫ

**(яңа редакциядә)**

**Казан шәһәре**
**Татарстан Республикасы**
**2017**

**Эчтәлек**

1 статья. Гомуми нигезләмәләр. 3

2 статья. Берлекнең юридик статусы 4

3 статья. Берлекнең максатлары, бурычлары, принциплары, эшчәнлек предметы. 5

4 статья. Берлекнең хокуклары һәм вазыйфалары 6

5 статья. Берлек әгъзалыгы. Берлек әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары. 8

6 статья. Берлекнең идарә органнары. 10

7 статья. Берлекнең структурасы 16

8 статья. Берлекнең мөлкәте. 16

9 статья. Берлектә исәп һәм хисап алып бару 17

10 статья. Берлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе 17

11 статья. Берлекне яңадан оештыру һәм бетерү тәртибе 17

## 1 статья. Гомуми нигезләмәләр.

1.1.«Бөтендөнья татар конгрессы» иҗтимагый берләшмәләренең халыкара берлеге, алга таба «Берлек» дип аталып, иҗтимагый берләшмәләр – юридик затларның уртак эшчәнлек алып баруы һәм аларның гомуми мәнфәгатьләрен яклау, Берлекнең һәм аның берләшмәләренең уставта билгеләнгән максатларына ирешүе өчен оештырылган халыкара иҗтимагый берләшмәсе булып тора.

1.2. Берлек үз эшчәнлеген әгъзаларының иреклелек һәм тигез хокуклылыгы принципларында, үзидарә, Россия Федерациясе Конституциясе һәм законнары, гамәлдә булган халыкара хокук принциплары һәм нормалары, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре һәм әлеге Устав нигезендә алып бара.

1.3. Берлек дәүләт теркәве узган көннән юридик зат булып таныла, ул аерымланган мөлкәткә һәм мөстәкыйль балансқа ия.

1.4. Берлекнең рус телендәге тулы атамасы: Международный Союз общественных объединений «Всемирный конгресс татар».

1.5. Берлекнең рус телендәге кыскартылма атамасы: МСОО «Всемирный конгресс татар», Всемирный конгресс татар, ВКТ.

1.6. Берлекнең татар телендәге тулы атамасы: «Бөтендөнья татар конгрессы» иҗтимагый берләшмәләренең халыкара берлеге.

1.7. Берлекнең татар телендәге кыскартылма атамасы: Бөтендөнья татар конгрессы, БТК.

1.8. Берлекнең инглиз телендәге тулы атамасы: International Union of public associations «World congress of the tatars».

1.9. Берлекнең инглиз телендәге кыскартылма атамасы: IUPA «World congress of the tatars», World congress of the tatars.

1.10. Берлекнең оештыру-хокукый формасы – иҗтимагый берләшмәләр берлеге.

1.11. Берлекнең территориаль статусы – халыкара иҗтимагый берләшмә.

Берлек үз эшчәнлеген Россия Федерациясе, БДБ илләре һәм чит ил дәүләтләре территориясендә алып бара.

1.12. Берлек – коммерциячел булмаган оешма һәм табыш алу аның эшчәнлеге максаты булып тормый.

1.13. Берлек хөкүмәт оешмасы булып тормый, дәүләт хакимияте органнары функциясен башкармый, тынычлык урнаштыру эшчәнлеген башкара, халыкара оешмалар белән бәйләнешне тормышка ашыра.

1.14. Уставта билгеләнгән максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру өчен Берлек дәүләт органнары, мәдәни-мәгърифәти учреждениеләр, милли-мәдәни берләшмәләр, ассоциацияләр, сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, дини оешмалар, аерым гражданнар белән хезмәттәшлек итә.

1.15. Берлекнең даими гамәлдә булган җитәкчелек итү органы – Берлекнең Милли Шурасы (Национальный Совет Союза, National Council of the Union) урнашкан урын: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре.